СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30 июль, 2026 ел № 94

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 13 апрелендәге 138 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы прокуратурасының 2026 елның 29 июнендәге 02-08-01 номерлы протесты нигезендә, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2017 елның 13 апрелендәге 138 номерлы карары белән (13.10.2017 № 168, 11.07.2018 № 226, 28.08.2018 № 202, 31.08.2018 № 238, 17.04.2019 № 287, 22.05.2020 № 371, 07.06.2023 № 304, 26.03.2024 № 399, 15.08.2024 № 429, 21.11.2024 № 467 карарлары редакциясендә) расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне:

1.1. 8.1 пунктның 1 пунктчасындагы 4 абзацында «, муниципаль берәмлекнең Сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 8.1 пунктның 2 пунктчасындагы 2 абзацында «, муниципаль берәмлекнең Сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. 8.1 пунктның 2 пунктчасындагы 3 абзацында «, муниципаль берәмлекнең Сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.4. 8.1 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) ул муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән йә, әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса, турыдан-туры аңа буйсынган яисә аның

контролендә тотылган җирле үзидарә органында өченче затлар эшләре буенча ышанычлы яисә вәкил булырга;»;

1.5. 8.1 пунктның 5 пунктчасында «муниципаль берәмлекнең Сайлау комиссиясенә җирле үзидарә органнары белән, башка муниципаль берәмлекләрнең Сайлау комиссияләре белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.6. 8.1 пунктның 8 пунктчасында «муниципаль берәмлекнең Сайлау комиссиясенә һәм аларның җитәкчеләренә» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча игълан итәргә һәм Интернет-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф. Хисамутдинов